УПРАВЛЕНИЕ ЗАГС
КАБИНЕТА МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Улица Ахтямова, дом 14,
город Казань, 420021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫНЫҢ
ГХАТ ИДАРӘСЕ
Әхтәмов урамы, 14 нче йорт,
Казан шәһәре, 420021

Тел./ факс: (843) 293-14-89, zags@tatar.ru, zags.tatarstan.ru

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**Казан шәһәре**

22 ноябрь, 2022 ел. № 46

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсенең 2013 елның 17 декабрендәге 144 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсе тарафыннан апостиль кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы ГХАТ идарәсе тарафыннан Татарстан Республикасында гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу өчен вәкаләтле булган органнар тарафыннан бирелгән гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турындагы документларга апостиль кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын һәм үтемлелек дәрәҗәсен яхшырту максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсенең «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсе тарафыннан апостиль кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 17 декабрендәге 144 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсенең 2016 елның 28 сентябрендәге 62 номерлы, 2018 елның 19 июнендәге 35 номерлы, 2018 елның 24 октябрендәге 85 номерлы, 2019 елның 29 октябрендәге 82 номерлы, 2020 елның 30 сентябрендәге 44 номерлы, 2021 елның 22 ноябрендәге 69 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсе тарафыннан апостиль кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертеп, 2.12 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.12. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры.

Мөрәҗәгать итүчене кабул итүне (аңа хезмәт күрсәтелүне) көтү һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алуның максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

Мөрәҗәгать итүчеләр өчен алдан язылу мөмкинлеге бирелә, ул Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (http://uslugi.tatarstan.ru) гамәлгә ашырыла.

Алдан язылу буенча гариза тапшырганда чират көтүнең максималь чоры алдан язылу буенча билгеләнгән вакытны 5 минуттан да күбрәккә арттырып җибәрә алмый.

Кабул итү буенча билгеләнгән вакыттан соң 15 минут узгач мөрәҗәгать итүче килмәгән очракта, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язылу буенча мөрәҗәгать итүчеләр булмаган очракта, мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итү чират тәртибендә башкарыла.».

2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Идарә җитәкчесе Г.Р.Нигъмәтуллина